КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 ноябрь г.Казань № 1149

2022 елда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында «Алабуга» IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү үзәген булдыру чараларын тормышка ашыру турында

Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указын тормышка ашыру, «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешү максатларында, шулай ук 2020 – 2022 елларда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында «Балаларга цифрлы белем бирү үзәкләрен булдыру» чарасы (2 чират) буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидия бирү өчен Россия Федерациясе субъектларын сайлап алуны үткәрү буенча Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы комиссиясе утырышының 2019 елның 28 августындагы МР-32/02пр номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын 2022 елда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында «Алабуга» IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү үзәген булдыру чараларын тормышка ашыру буенча төбәк координаторы итеп билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән «Алабуга» IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү үзәген булдыру һәм аның эшчәнлеге буенча чаралар комплексын (юл картасын) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында «Алабуга» IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү үзәген булдыру чараларын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 14 август, 678 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 ноябрь, 1149 нчы
карары белән расланды

«Алабуга» IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү
үзәген булдыру һәм аның эшчәнлеге буенча
чаралар комплексы (юл картасы)

| Т/с | Чара исеме | Җаваплы | Нәтиҗәсе | Срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Түбәндәгеләрне раслау:<br>«Алабуга» IT-кубы» балаларга цифрлы белем бирү үзәген (алга таба – Үзәк) булдыру һәм аның эшчәнлеге өчен җаваплы төбәк ведомство проект офисы составындагы вазыйфаи затны;<br>Татарстан Республикасы территориясендә Үзәк булдыру һәм аның эшчәнлеге концепциясен, шул исәптән:<br>Үзәкнең урнашу урынын (адресын, урыннар мәйданын, халык өчен транспорт белән бару мөмкинлеген);<br>Үзәк булдыру һәм аның эшчәнлеге күрсәткечләре исемлеген;<br>Үзәкнең белем бирү юнәлешләре исемлеген | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Алабуга» сәнәгать җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2021 елның 30 ноябреннән дә соңга калмыйча |
| 2. | Үзәкне җиһазландыру өчен инфраструктура кәгазен формалаштыру һәм раслау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | өстәмә һөнәри белем бирүче «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының Дәүләт сәясәтен һәм мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри үсешен тормышка ашыру академиясе» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (алга | федераль оператор тарафыннан җибәрелә торган график буенча |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | таба – федераль оператор) адресына хат;<br>килештерү турында федераль оператор хаты;<br>Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | |
| 3. | Үзәк урыннарының бертип дизайн-проектын һәм зоналарга бүленешен булдыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | урыннарның бертип дизайн-проектын һәм зоналарга бүленешен килештерү турында федераль оператор адресына хат;<br>урыннарның бертип дизайн-проектын һәм зоналарга бүленешен килештерү турында федераль оператор хаты;<br>урыннарның бертип дизайн-проектын һәм зоналарга бүленешен раслау турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2022 елның 1 февраленә кадәр |
| 4. | Үзәкне булдыру өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында белдерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | белдерүләр реестры (федераль оператор формасы буенча) | 2022 елның 15 феврале |
| 5. | Үзәк булдырыла торган мәгариф оешмасы турында мәгълүмат бирү характерындагы белешмә кәгазен әзерләү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | белешмә кәгазе («Мәгариф» илкүләм проектының ведомство проект офисы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча) | 2022 елның 30 июненнән дә соңга калмыйча |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 6. | Үзәкнең штат расписаниесен раслау (Үзәк булдырылган оешманың штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ локаль акты | 2022 елның 25 августы |
| 7. | Үзәк булдыру кысаларында матди кыйммәтләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне кабул итүне раслый торган документлар реестрын формалаштыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | белешмә кәгазе (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы яки федераль оператор тарафыннан билгеләнә торган форма буенча) | 2022 елның 25 августыннан да соңга калмыйча |
| 8. | Үзәк урыннарын Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының методик тәкъдимнамәләренә туры китерү буенча фотомониторинг үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | хисап (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы яки федераль оператор тарафыннан билгеләнә торган форма буенча) | 2022 елның 25 августыннан да соңга калмыйча |
| 9. | Үзәкнең балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлегенә лицензия алу (кирәк булганда) | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга лицензия | 2022 елның 25 августыннан да соңга калмыйча |
| 10. | «Мәгариф» илкүләм проекты, шул исәптән Үзәк инфраструктурасына оештыру ягыннан һәм методик яктан ярдәм күрсәтү чараларының бердәм комплекслы планын формалаштыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы | 2022 елның 25 августыннан да соңга калмыйча |
| 11. | «Алабуга» IT-кубы» цифрлы белем бирү үзәге эшли башлау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, | массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту, мәгариф оешмасы сайтында | 2022 елның 15 сентябре |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | Үзәк турында язылган бүлек булу | |
| 12. | Үзәкне булдыру һәм анын эшчәнлеге күрсәткечләре үтәлешенә квартал саен мониторинг үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | федераль операторга күрсәткечләр мониторингы йомгаклары буенча хисап | 2022 елның 1 октябре, алга таба – квартал саен |
| 13. | Үзәкнең укыту һәм тәрбия бирү чараларын файдаланып, мәгариф программаларын тормышка ашыручы педагогик хезмәткәрләрнең (федераль оператор реестрыннан программалар буенча) квалификациясен күтәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор, «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | педагогик хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү турында документлар | 2022 ел дәвамында |